Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
«Яңа Кади авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнары җыены
карары

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең составына керүче
Кызыл Чишмә авылы торак пунктында

11 ноябрь 2019 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Кызыл Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда гражданнарның үзара салымын Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Кызыл Чишмә авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 550 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Утыз Имән торак пунктында , һәм Кызыл Чишмә авылында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Утыз Имән торак пунктындагы 1, 4 номерлы зиратны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру, ремонтлау, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, проект-смета документлары өчен түләү, әлеге эшләрне( хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Утыз Имән торак пунктында 4(дүрт) тавыш әйткеч урнаштыру, 3 км кабель монтажлау;
- Совет урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү, Утыз Имән торак пунктында 200 метр (20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алу);
- Утыз Имән авылының 1 һәм 2 номерлы скважиналарын лицензияләү буенча документация өчен түләү.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы М.М.Әминов